Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Елаур авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 89 «25» октябрь 2019 ел

Елаур авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Елаур авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 19 июлендәге 83 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында» 2013 елның 25 июнендәге 50 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында» һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 19 июлендәге 83 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә”гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 бүлегенең 3.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Җирлектә муниципаль хезмәт Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы кодексы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль берәмлек Уставы, әлеге Нигезләмә, башка муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.».

1.2. Нигезләмәнең 7 бүлегенең 7.4 бүлегендәге 6 пунктчасында «Мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш,;» сүзләрен «индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәлүне раслаучы документ;». сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 13 бүлекнең 13.3 пунктның икенче абзацында "Ә стажның озынлыгы һәм айлык түләүләр муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен билгеләгәндә муниципаль хезмәткәргә билгеләнгән шундый ук мәгънәләрдә исәпкә алына.» сүзләрен «ә класс чины өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын билгели торган норматив хокукый актында билгеләнгән мәгънәдә исәпкә алына.» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. Нигезләмәнең 21 бүлегенең 21.13 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«21.13. Әлеге бүлекнең 21.12 пункты нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-

ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акчаларны һәм кыйммәтләрне саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты җирлекнең Башкарма комитеты җитәкчесе депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә күрсәтелгән затларга карата тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка башка җаваплылык чараларын куллану турында гариза белән мөрәҗәгать итә.».

1.5. Нигезләмәнең 34 бүлегенең 34.2 пунктындагы “а" пунктчасында "Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнә торган граждан белән хезмәт шартнамәсе төзегәндә эш бирүченең Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнә торган граждан белән хезмәт шартнамәсе төзегәндә, дәүләт яисә муниципаль хезмәттән азат ителгәннән соң 2 ел дәвамында аның соңгы хезмәт урыны буенча дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрне эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә мондый шартнамә төзү турында шартнамә төзү хакында эш бирүче тарафыннан хәбәр итү тәртибе турында» 2010 елның 8 сентябрендәге 700 номерлы РФ Хөкүмәте Карары»; сүзләрен «Эш бирүче тарафыннан дәүләт яисә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән (исемлеге Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнә) граждан белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яисә граждан-хокукый шартнамәсен төзү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау хакында»2015 елның 21 гыйнварындагы 29 номерлы Хөкүмәт карары;» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Елаур авыл җирлеге
Советы рәисе О.В.Охотникова